**ГЛАВА**
**Новобизякинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Яңа Бәзәкә авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2023 № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Бәзәкә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 24 ноябрендә 11 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә ласларга: «2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Бәзәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү).

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту,транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системалары өчен материаллар һәм электр товарлары сатып алу; коены ремонтлау һәм аңа якын территорияләрне төзекләндерү; чишмә территориясен төзекләндерү ).

3. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Яңа Бәзәкә авылы Тукай урамы өчен вак таш сатып алу һәм җәю; үләннәрне чабу һәм торак пункт урамнарын кардан чистарту)

4. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү ( запас частьләр, дизель ягулыгы алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу); рөхсәтсез чүплекләрне бетерү; Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен һәйкәлне яңарту).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Яңа Бәзәкә авылы, Тукай урамы, мәктәп янындагы мәйданчыкта буенча үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.С.Салихов